РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**МУСЛЮМОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУСЛЮМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

№ _06__

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**МӨСЛИМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

*«_18_»__март_2021 ел*

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы “Мөслим авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 4 сентябрендәге 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү өлкәсендә программалар һәм проектларны башкару буенча муниципаль берәмлек вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 1.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.9. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасы булып, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын төзү өчен һәм аларга ярдәм күрсәтү өчен шартлар тәэмин итүче Россия Федерациясе дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын), Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын), муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) гамәлгә ашырганда, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны башкару өчен үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы яисә тәэмин итеп торучы (башкаручы, подрядчы) оешмалар системасы тора».

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканан соң үз көченә керә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.З.Сәхбетдинов